**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 7 октябрь № 725

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 12 февраль, 38 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 12 февраль, 38 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 27 июнь, 515 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2012 ел, 31 август, 746 нчы; 2013 ел, 14 март, 160 нчы; 2013 ел, 29 август, 611 нче; 2014 ел, 28 март, 194 нче; 2014 ел, 7 июнь, 388 нче; 2014 ел, 30 август, 630нчы; 2015 ел, 21 октябрь, 789 нчы; 2015 ел, 29 декабрь, 1001 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 пунктта:

3.3.1 пунктчада:

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданнар, юридик затлар билгеләнгән тәртиптә тапшырган урманнарны саклау турында хисапларны, урманнарны яклау турында хисапларны карап ткишерә;»;

уникенче абзацта «урман янгыннарын сүндерү» сүзләреннән соң «, урман янгыннарын локальләштерү һәм бетерү максатларында шартлату эшләрен башкару һәм урман янгыннарын сүндерү максатларында янгыннарны ясалма яудыру буенча чараларны гамәлгә ашырудан тыш» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«урман патологиясен тикшерү нәтиҗәләре буенча урман патологиясен тикшерү актын раслый, аны раслаган көннән соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә вәкаләтле органның рәсми сайтында урнаштыра һәм ведомствоара электрон багланышларның бердәм системасыннан яки гомуми кулланылыштагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, көчәйтелгән квалификацияләнгән электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтләр биргән федераль башкарма хакимият органына җибәрә.»;

3.3.4 пунктчаның унынчы абзацында «үсемлек дөньясы объектлары» сүзләрен «хайваннар һәм үсемлекләрнең сирәк очрый торган һәм югалу куркынычы булган төрләре» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 3.3.8 пунктча өстәргә:

«3.3.8. Татарстан Республикасының террорчылыкка карыш тору өлкәсендә вәкаләтләре:

террорчылыкка каршы тоту буена чараларны гамәлгә ашырганда укулар үткәрүдә катнаша;

Министрлыкның террорчылык чагылышлары нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү өчен билгеләнгән көчләрен һәм чараларын нәтиҗәле файдалануга даими әзерлек хәлендә тота.»;

түбәндәге эчтәлекле $5.4^1$ пункт өстәргә:

«$5.4^1$. Министрлыкның структур бүлекчәләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү министр боерыгы белән расланган нәтиҗәлелек күрсәткечләре исемлеге нигезендә гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карарның 1 пунктындагы дүртенче, бишенче, җиденче һәм сигезенче абзацлар 2016 елның 1 октябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2016\725.docx